# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАЛМАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«30» июль 2019 ел Калмаш авылы № 13

Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлеге территориясендә алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлаулар буенча сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннарны билгеләү турында

Татарстан Республикасы Сайлау Кодексының 64 маддәсе 8 өлеше һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауларда сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар бүлеп бирү һәм җиһазлау турында Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү хакында» 2019 елның 10 июлендәге 67/516 санлы карары нигезендә Тукай муниципаль районы Калмаш авылҗирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлеге территориясендә алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлаулар буенча сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен түбәндәге махсус урыннарны билгеләргә:

– Калмаш авылы, З.Галиев ур., 15 й., мәгълүмат стенды;
– Калмаш авылы, Үзәк ур.,36 й., мәгълүмат стенды;
- Калмаш авылы, Советлар ур.,33А й., мәгълүмат стенды;
– Калмаш авылы, Үзәк ур., 44 й., мәгълүмат стенды;
– Калмаш авылы, Тукай ур., 42 й., мәгълүмат стенды;
– Калмаш авылы, Яңа ур., балалар уен площадкасында мәгълүмат стенды;
– Игенче авылы, Үзәк ур., 33 й., мәгълүмат стенды

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырып халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (http://tukay.tatarstan.ru) «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үзҗаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Р.К.Габдуллина